Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының утыз бишенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

19 октябрь, 2023 ел

№ 262

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставының үз көчен югалтуын тану хакында» 2022 елның 29 декабрендәге 612-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында гавами тыңлауларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2015 елның 30 гыйнварындагы 3/224 номерлы Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районында гавами тыңлауларны, җәмәгать фикер алышуларын оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәгә (2017 елның 7 декабрендәге 120, 2019 елның 25 июлендәге 211, 2019 елның 24 октябрендәге 225 номерлы, 2022 елның 8 декабрендәге 203 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 10 өлешнең 10.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.4. Районның генераль планы проекты буенча иҗтимагый фикер алышулар яисә гавами тыңлаулар уздыру срогы, җәмәгатьчелек фикер алышулары нәтиҗәләре турында бәяләмә басылып чыккан көнгә кадәр, район халкына аларны уздыру вакыты һәм урыны турында хәбәр иткән мизгелдән алып бер айдан да артмаска тиеш»;

1.2. 11 өлешнең 11.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.3. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча иҗтимагый фикер алышуларның яисә гавами тыңлауларның озынлыгы мондый проект басылып чыккан көннән бер айдан да артык түгел.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов